**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2019 елның 16 ноябре № 1
Кодаш авылы, авыл Мәдәният йорты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авылы җирлеге торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәрбер балигъ булган кешедән, 1 группа инвалидларыннан, өч яки аннан да күбрәк балигъ балалары булмаган күп балалы гаиләләрдән тыш, үзара салым кертү буенча 2020 елда 300 сум салым алу һәм шул җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итү һәм түбәндәге эшләр өчен:

-Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Кодаш торак пунктының зиратларын тәртиптә тоту, карау өчен.

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 544 граждан кертелгән, җыенда катнашучылар саны 279 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 279 кеше тавыш бирде;

җыенда катнашучы 0 кеше «юк» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше канәгать калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылының торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - гамәлгә яраклы дип таныргa.

2«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авылы җирлеге торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәрбер балигъ булган кешедән, 1 группа инвалидларыннан, өч яки аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән тыш, үзара салым кертү буенча 2020 елда 300 сум салым алу һәм шул җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итү һәм түбәндәге эшләр өчен:

-Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Кодаш торак пунктының зиратларын тәртиптә тоту, карау өчен дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны Кодаш авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталы «Интернет» челтәрендә (http://bugulma.tatar.ru, «Кодаш авыл җирлеге» бүлекчәсендә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**Кодаш авыл җирлеге башлыгы**
**гражданнар җыенында рәислек итүче Г.А.Хәйрсарова**